ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31.07.2024 г.Лениногорск № 198

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2015 елның 18 ноябрендәге 38 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерүнең яңа редакциядә кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 131-ФЗ номерлы, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы РФ Законы нигезендә, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2015 елның 18 ноябрендәге 38 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерүнең яңа редакциядә кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«Йорт хайваннарын һәм кошларын тоту» бүлеген 132 пункттан 155 пунктка кадәр төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикаторда-«Лениногорские вести» газетасында һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры — Р.Г. Хөсәенов